Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

17 апрель 2023 ел № 3

Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 31 августындагы 12 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында» 2021 елның 12 маендагы 55нче номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары, 2022 елның 1 мартыннан кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешү нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 10 апрелендәге 02-08-01/149 номерлы протестын карап

Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 31 августындагы 12 номерлы карарының үз көчен югалткан дип танырга.

2 Әлеге карарны Молодежный бистәсе, Мәктәп урамы, 3 йорт, Дербедень авылы, Совет урамы, 32А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әлмәт авыл башкарма
комитеты җитәкчесе В.И.Газизова